Туган телем - иркә гөлем, киндер сиңа күңел түрем...

# Кумәк көч

ГОМУМИ РАЙОН ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 47 (10687)
Чәршәмбе,
23 ноябрь 2016 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1)2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы эшчеләр бистәсе, Пионерская урамы, 30)

# АШЫГЫЧ ЯРДӘМГӘ - ЯРДӘМ






Ульяновск өлкәсе Губернаторы С. И. Морозов регионда сәламәтлек саклау учреждениеләренең тормышы белән даими кызыксынып яши һәм «Земский фельдшер» программасын реализацияләүне үз контролендә тота.

Югарыда әйтеп үткән программа нигезендә соңгы елларда район больницалары бихисап җиһазлар, төрле маркалы техникалар белән тәэмин ителде. Бу юнәлештә аеруча «Ашыгыч ярдәм» службаларына зур игътибар бирелә башлады. Мәсәлән, 2013 елда өлкә Губернаторы С. И. Морозов район больницасына өч «УАЗ» маркалы автомобиль базасында «А» класслы ашыгыч ярдәм күрсәтү машиналарын тапшырды .

Быел, 16 ноябрь көнне, өлкә Губернаторы С. И. Морозов кулыннан 16 район больницасы «В» класслы ашыгыч ярдәм күрсәтү реамобильләренең ачкычларын алдылар. Бу исемлектә безнең Иске Кулаткы районы да бар иде.

- Бу безнең өчен зур шатлык, коллективыбыз исеменнән өлкә Губернаторы С. И. Морозовка олы рәхмәтләребезне җиткерәбез, - дип сөйли Иске Кулаткы район больницасының баш врачы Сергей Кунеевский.

- Гомумән әйткәндә, хәзер ашыгыч ярдәм күрсәтү службасының техник паркы тулаем яңартылды. Соңгы модельдә булган «В» класслы реамобиль алу тагын да шатландыра, чөнки анда әлеге заман таләбенә туры китереп ясалган бихисап медицина җиһазлары урнаштырылган. Ә бу исә критик хәлдә булган авыруларның гомерен саклап калуга зур гарантия бирә.

Әлеге реамобильне караганнан соң, медицина тармагының үсешен чынбарлыкта күреп була. Бу машинаның салоны эчендә авырулар өчен сулыш алу аппаратуралары да, глюкометр да, наркоз бирү өчен кирәкле җайланмалар да һ. б. куелган. Аның «УАЗ» маркалы автомобильдә булуы да өстенлек бирә, чөнки авыл җирендә начар юллардан тиз арада авыру янына барырга ышаныч тудыра.

Хәзерге вакытта безнең Иске Кулаткы район больницасының карамагында дүрт яңа ашыгыч ярдәм күрсәтү машинасы тәүлек буе район халкының сәламәтлеге сагында торалар. Район халкыбызның исән булуын һәм әлеге машиналарның һәрвакыт төзек хәлдә, дежурда гына басып торуларын теләп калабыз.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**

**Автор фотосы.**

***Регина Азизова - врач-анестезиолог:***

***Иске Кулаткы район больницасына камилләштерелгән, яңа реамобильнең кайтуына районыбыз халкы да, медицина хезмәткәрләре дә бик шатланды. Чөнки бу өлкә Губернаторы С. И. Морозовның регионыбызда яшәүчеләрнең сәламәтлеген кайгыртуы турында ачыктан-ачык сөйли.***

***Реамобильнең салоны эчендә, тулаем күләмдә, барлык реанимацион чараларны да үткәреп була.***

***Мин, яшь табиб буларак, районыбызның авылларына чыгып, авыруларга еш кына ашыгыч ярдәм күрсәтәм. Элек аларга беренче ярдәм генә күрсәтә идек, ә әлеге машина салонындагы медицина җиһазлары белән авыруларны дәвалауга ук керешергә була. Андагы уңайлыклардан файдаланып, кешене үлем тырнагыннан да коткарырга мөмкин.***

***Шушы уңайлыкларны тудыруда ярдәм күрсәткән, район больницасына яңа машина тапшырган өчен медицина хезмәткәрләре һәм шәхсән үземнең исемемнән өлкә Губернаторы С. И. Морозовка олы рәхмәтләремне җиткерәм.***

***Суфия Мамадалеева - өлкән фельдшер:***

***Мин озак еллар район больницасында өлкән фельдшер булып хезмәт итәм. «Земский фельдшер» программасын тормышка ашыру йөзеннән өлкә Губернаторы С. И. Морозов безнең район больницасына яңа реамобиль тапшырды.***

***Бу бик әйбәт, чөнки безнең эш сыйфатлы медицина күрсәтү белән оперативлык таләп итә.***

***Ашыгыч ярдәм күрсәтү службасы кешеләрне үлемнән коткаруда зур эш башкара. Безгә еш кына критик хәлдә булган авыруларны Ульяновск, Барыш шәһәрләренә озатырга туры килә. Авыруларны әлеге реамобильдә алып барганда ук, аларны дәвалау өчен төрле процедураларны үткәрергә була һәм бу бик уңай.***

***Яңа реамобиль - төзек машина буларак, теләсә кайсы вакытта, теләсә нинди һава шартларында авыру янына тиз арада барып җитәргә мөмкинлек бирә.***

***Безнең медицина тармагын чын күңелдән кайгыртканы өчен өлкә Губернаторы С.И. Морозовка олы рәхмәтебезне белдерәбез.***

## ХӨРМӘТЛЕ ӘНИЛӘР!

Ноябрь аеның иң ямьле, затлы бәйрәмнәрнең берсе - Әниләр көне. Бу көнне кояш та җылырак яктырта, күңелләр дә шат. Әниләр көне уңаеннан чын күңелдән тәбрикләү кабул итегез. Бу гүзәл бәйрәм улларның да һәм кызларның да ихтирамын, мәхәббәтен, ихтирамын күрсәтеп кенә калмый, ә җәмгыятьтә ананың мөһим ролен дә тасвирлый. Әйе, дөньябызда алтыннан да кыйммәтрәк, биек таулардан да биегрәк, чиксез галәмгә тиң бары тик кадерле әниләребез. Кадерле әниләребез! Сезгә сәламәтлек, гаилә тынычлыгы, балаларыгызның һәм оныкларыгызның игелеген күреп, алар турында гел яхшы сүзләр генә ишетергә язсын. Бәхетле, исән-сау булыгыз!

**Э.Ә. Ганеев,**
**Иске Кулаткы районы Башлыгы.**
**И.А. Аблязов,**
**Иске Кулаткы район администрациясе Башлыгы.**

## ХӨРМӘТЛЕ ГАЗЕТА УКУЧЫЛАР!

**“Кумәк көч”кә язылу дәвам итә. Алты айга язылу бәясе – 349 сум 26 тиен. Киләсе елда да бергә булыйк!**



## ӘНИЛӘР БӘЙРӘМЕНӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

**24 ноябрь көнне район мәдәният йортында Әниләр көненә багышланган бәйрәм булачак. Ул 14 сәгатьтә башлана. Программада районыбыз һәвәскәр артистлары көче белән әзерләнгән зур концерт, әниләрне хөрмәтләү булачак. Районыбызның барлык әниләре дә әлеге бәйрәм чарасына чакырыла.**

**Рәхим итегез, килми калмагыз!**

| ПӘНҖЕШӘМБЕ (24.11.) | ҖОМГА (25.11.) | ШИМБӘ (26.11.) | ЯКШӘМБЕ (27.11.) | ДҮШӘМБЕ (28.11.) | СИШӘМБЕ (29.11.) | ЧӘРШӘМБЕ (30.11.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| - 5 | - 4 | - 4 | - 2 | - 3 | - 1 | - 1 |
| 0 | - 2 | - 2 | - 0 | - 2 | - 2 | - 5 |

## ЯҢАЛЫКЛАР



Россия Президенты Владимир Путин Федераль Җыенга юллама белән 8 декабрьдә мөрәҗәгать итәчәк, ә 22 декабрьдә йомгаклау конференциясендә 2016 елга нәтиҗәләр ясаячак. Бу хакта Хөкүмәткә һәм Дәүләт Думасына якын чыганакка сылтама белән “Известия” газетасы яза. РФ Президенты ел саен декабрь аенда Федераль Җыенга Юллама белән чыгыш ясый, Россия һәм чит ил журналистлары катнашында матбугат очрашуын үткәрә.

● ● ●

Россия Президенты В.В. Путин Перуда Азия – Тын океан экономик аралашу саммитында катнашты. Илләр арасында экономик эшчәнлек, сәүдә мөнәсәбәтләрен уңайлату, энергетика сферасында хезмәттәшлек итү мәсьәләләре каралды. Игътибар үзәгендә илгә инвесторлар тарту булды. Форум эшенә йомгак ясау буенча уздырылган пресс - конференциядә Владимир Путин үзенең бәясен бирде, журналистлар сорауларына җаваплар кайтарды. Саммитта катнашуның максаты халыкара сәүдә элемтәләрен ныгыту иде.

● ● ●

РФ Хөкүмәтенең беренче вице-премьеры Игорь Шувалов Россия икътисади үсеш министры урынбасарлары һәм структура бүлекчәләре җитәкчеләре белән эшлекле киңәшмә үткәргән. Ул ведомство хезмәткәрләренә «министрлык министрсыз озак тормас», дип белдергән.

● ● ●

Россиялеләр икенче географик диктант яздылар. Диктант Россиянең 85 төбәгендә үткәрелде. Бу чарада теләгән һәркем үз көчен сынап карый алды. Катнашучыларның яшьләренә һәм белемнәренә игътибар ителмәде.

Диктант 30 биремнән торган, аларны чишүгә 45 минут вакыт бирелгән.

Биремнәр өч өлешкә бүленгән иде. Беренчесе – географик атамаларны һәм терминнарны, икенчесе - картада географик объектларның урнашуын, өченчесе әдәби әсәрләрдән өзекләр буенча географик объектларны белү тикшерелә. Максималь бәя 100 балл.



Меңгә якын ульянлылар II Бөтенроссия географик диктантта катнаштылар. 20 ноябрьдә педагогия университетында Губернатор Сергей Морозов әлеге акциядә катнашучыларны сәламләп, тестированиене үтте. Әлеге акциянең төп максаты – россиялеләрдә илебезгә, кече Ватанга мәхәббәт, кызыксыну уяту, Россиянең тарихы, казанышлары, бөеклеге турында күбрәк белү.

● ● ●

Регион Башлыгы Сергей Морозов һәм һава-десантлы гаскәрләренең команда итүче, генерал-полковник Андрей Сердюков тантаналы рәвештә суворов хәрби училищесының тәрбиячеләрен һәм педагогларын уку йортының 25 еллыгы белән тәбрикләделәр.

● ● ●

Регион Башлыгы Сергей Морозов Ереваньдә үтәчәк "Контрафактка каршы – 2016" IV Халыкара форумында катнашачак. Әлеге чара 22-23 ноябрь көннәрендә үтәчәк. Форумда РФнең сәүдә һәм промышленность Министры Денис Мантуров, Армения Республикасы Хөкүмәтенең әгъзалары, илебезнең бизнес структурасы вәкилләре катнашалар.

---

Министерством здравоохранения, семьи и социального благополучия Ульяновкой области на территории Ульяновской области организована работа «горячей линии» по вопросам доступности и качества бесплатной медицинской помощи населению.

Одной из основных задач контактного центра является оказание консультативной помощи гражданам в режиме реального времени.

Звонки по телефону «горячей линии» (8-800-200-7307) принимаются с понедельника по пятницу с 8.00 до 19.00 ч., в субботу - с 8.00 до 15.00 ч . В остальное время суток граждане могут оставить голосовое сообщение, которое в последующем будет рассмотрено.

---

**ВНИМАНИЮ РАБОТОДАТЕЛЕЙ! СРОЧНО!**

**УВАЖАЕМЫЕ РУКОВОДИТЕЛИ ПРЕДПРИЯТИЙ, КАДРОВЫЕ РАБОТНИКИ!**

До 1 декабря текущего года работодатели, имеющие среднесписочную численность не менее 35 человек обязаны предоставить в службу занятости сведения по установленной форме о рассчитанном ими числе инвалидов, подлежащих приему на работу в счет квоты в 2017 году (ст.2 Закона Ульяновской области от 27.04.2009 г. №41-ЗО «О квоте для приема на работу инвалидов на территории Ульяновской области и признании утратившими силу отдельных законодательных актов (положений законодательных актов) Ульяновской области».

Работодатели в соответствии с установленной квотой для приема на работу инвалидов обязаны создавать или выделять рабочие места для трудоустройства инвалидов и принимать локальные нормативные акты, содержащие сведения о данных рабочих местах (пункт 1 статьи 24 ФЗ от 24.11.1995 №181-ФЗ «О социальной защите населения инвалидов в РФ»).

За неисполнение работодателем обязанности по созданию или выделению рабочих мест для трудоустройства инвалидов в соответствии с установленной квотой для приема на работу инвалидов наступает ответственность в виде наложения административного штрафа на должностных лиц в размере от пяти до десяти тысяч рублей (ст.5.42 Кодекса РФ об административных правонарушениях).

**По вопросам квотирования инвалидов обращаться в ОГКУ ЦЗН Старокулаткинского района по адресу: р.п.Старая Кулатка ул.Пионерская д.12, тел.:8-84(249)2-16-78.**

---

**ГОРЯЧАЯ ЛИНИЯ**

25 ноября 2016 года в Управление Пенсионного фонда в Старокулаткинском районе пройдет «горячая линия» по вопросам распоряжения средствами материнского (семейного) капитала. На вопросы населения ответят специалисты с 09.00 до 12.00 часов. Ждем ваших звонков по телефону: 2-28-55.

---

ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

# ЯКТЫ БУЛСЫН УРАМНАР

Ноябрь аенда көннәр нык кыскарып, төннәр озайгач, урамнарны яктырту мәсьәләсе тагын да актуальләшә. Иртән эшкә барганда да, кайтканда да бик караңгы, хәтта багана башларында ут янып торса да. Транспорт күп йөри торган урамнарда юл аркылы чыгу аеруча катлаулы: җәяүлеләр өчен дә, автомобиль йөртүчеләргә дә. **Районыбыз урамнарын яктырту мәсьәләсенә ачыклык кертү максатыннан без “Транстехсервис” муниципаль учреждениесенең энергетика буенча белгече Равил Шәүкәтович Байгузинга мөрәҗәгать иттек.**



- Хәерле көн, иң беренчедән, мин газета укучыларыбызны урамнарны яктырту челтәренә кагылышлы саннар белән таныштырып үтәр идем. Иске Кулаткы муниципаль берәмлеге буенча урамнарны яктырту челтәренең озынлыгы 168 км. һәм 820 яктырту ноктасы тәшкил итә. Шул исәптән Иске Кулаткы шәһәр поселениесендә – 88 км. озынлыкта, 461 нокта, ел дәвамындагы чыгымнар уртача 357788 кВт.сәг. тәшкил итә. “Мостяк” авыл поселениесендә – 15,75 км. озынлыкта, 63 нокта, ел дәвамындагы чыгымнар уртача 33612 кВт.сәг. тәшкил итә. “Атлаш” авыл поселениесендә - 13,4 км. озынлыкта, 70 нокта, ел дәвамындагы чыгымнар уртача 27747 кВт.сәг. тәшкил итә. “Зеленай” авыл поселениесендә - 32 км. озынлыкта, 128 нокта, ел дәвамындагы чыгымнар уртача 24774 кВт.сәг. тәшкил итә. “Терешка” авыл поселениесендә – 26,8 км. озынлыкта, 98 нокта, ел дәвамындагы чыгымнар уртача 380000 кВт. сәг. тәшкил итә. Район администрациясе, чыгымнарны киметү максатыннан, 15 мең сум күләмендә АПЭЛ фирмасының “ТО-2” вакыт исәпләү җиһазларын сатып алды һәм алар Иске Кулаткы эшчеләр бистәсенең 12 ноктасына урнаштырылды. Электрүткәргеч челтәренә реконструкция ясалып торган урамнарда исәпләү җиһазлары һәм вакыт таймерлары бердән урнаштырыла. Ноябрь аена Иске Кулаткы эшчеләр бистәсенең Советский, Куйбышев, Муса Җәлил, Метро, Пионерский, Калинина, Урицкий, Северный, Киров, Красноармейский, Комсомольский, Коммунальный, Прудный урамнары вакыт таймерлары ярдәмендә яктыртыла. Башкача әйткәндә, кояш баткач, баганадагы утлар кабына, 00.30 сәгатьтә сүнә һәм иртәнге 5.30 сәгатьтә кабынып, кояш чыкканчыга кадәр яктылык бирелә. 2015 елда “Энергосервис Волги” предприятиесе белән төзелгән контракт нигезендә Яңа Кулаткы, Усть Кулаткы, Бахтеевка, Иске һәм Яңа Яндука авылларында 220 яктырту ноктасы энергия саклаучы светоидиодлы лампаларга алмаштырылды. Әлеге эшләр 2016 елның беренче кварталында төгәлләнде. Яктырту нокталарын заманча лампаларга алмаштыргач, 2015 елның шушы чоры белән чагыштырганда, чыгымнарның күләме 56222кВт. кимеде. Иске Кулаткы эшчеләр поселогының Прудный, Коммунальный һәм Комсомольский урамнарындагы электрчелтәргә реконструкция эшләре башкарылды, анда исәпләү җиһазлары һәм вакыт таймерлары урнаштырылды, яктырту лампаларының көчлелеге 1,2 кВт. киметелде. Бу инде үз чиратында айлык чыгымнарны да 360 кВт. киметергә ярдәм итте. Район Башлыгы Э. Ә. Ганеевның спонсорлык ярдәме белән “Мостяк” авыл поселениесенә 64 энергия саклаучы яктырту лампалары урнаштырылды. Барчабызга да билгеле булганча, “Сабантуй – 2016” мәйданчыгын электрификацияләү буенча зур күләмле эшләр башкарылды.

**- Равил Шәүкәтович, Иске Кулаткы эшчеләр бистәсендә яшәүчеләрне урамдагы утларның төнлә сүнүләре борчый. Моның турында нәрсә әйтә аласыз?**

- Инде әйтеп үткәнемчә, яктырту нокталарына вакыт таймерлары урнаштырабыз, бу эшләр һәммәсе дә чыгымнарны киметү максатыннан башкарыла. Бүгенге көндә зур шәһәрләр урамнары да шушы вакыт таймерлары белән генә яктыртыла. Өйләребездә дә бит йокларга ятканда утларны сүндереп ятабыз, чөнки аннан соң үзебезгә түләргә туры килә.

**- Равил Шәүкәтович, ә менә Яшьләр паркы, Советский тыкырыгы һәм башка шундый яктыртылмый торган урамнарга кайчан яктылык килер икән?**

- Дөрес, башкарасы эшләребез байтак әле. Бүгенге көндә без энергосервислы контракт төзүгә документлар рәсмиләштереп торабыз. Әлеге контракт нигезендә яктылык нокталарын светоидиодлы лампаларга алмаштырырга һәм яктылык булмаган урамнарга яңа электр челтәре урнаштырырга планлаштырабыз. 2017 елда бу эшләрне тормышка ашыруны башлап җибәрергә җыенабыз. Районыбыз урамнары якты һәм матур булсын өчен, без бөтен көчебезне куеп хезмәт итәргә әзер.

**- Эчтәлекле әңгәмәгез өчен рәхмәт сезгә. Эшегездә уңышлар телəп калабыз.**

**Әңгәмәне Гөлназ КУЗӘЕВА алып барды.**

---

# КҮҢЕЛЛЕ БӘЙРӘМДӘ



Мәктәпләрдә балалар гомуми белем алса, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә исә аларга үзләренең кызыксынуларын һәм иҗади сәләтләрен үстерергә мөмкинлекләр бирелә. Иске Кулаткы балалар сәнгать мәктәбе укучыларга музыкаль белем бирүдә, музыка сәнгатенә мәхәббәт тудыруда һәм аны пропагандалау буенча эш алып баруда зур роль уйный. Хәзерге вакытта биредә 156 бала белем ала. Шул исәптән 21 се яңа уку елында беренче сыйныфка бардылар.Үткән атнада балалар сәнгать мәктәбендә беренче сыйныфка керүчеләрне кабул итү бәйрәме оештырылды.Чарага әлеге мәктәптә укучы балалар һәм ата-аналар чакырылган иде. Сәнгать мәктәбе директоры Л.Р. Амирова беренче сыйныфка керүчеләрне истәлекле көннәре белән котлады, аларга иҗади уңышлар теләде һәм бүләкләр тапшырды.

Бәйрәмнең төп сәбәпчеләре кунакларга музыкаль чыгышлар бүләк иттеләр. Балаларның милли киемнәрдән тыпыр-тыпыр биюләре, сәнгатьле итеп шигырь сөйләүләре, музыкаль коралларда оста иттереп уйнаулары беркемне дә битараф калдырмады. Педагоглар әзерләгән биремнәрне укучылар бергәләп, тиз арада чиштеләр. Әлеге чара бер мизгелдәй үтеп, кунаклар күңелендә матур тәэсирләр калдырды.

**Ә. ЯФАРОВА.**

---

# ДИНИ ТӘРБИЯ

Рухи тәрбия мәсьәләсе җәмгыять тормышында игътибар үзәгендә тора. Чөнки әдәп-әхлак кыйммәтләре онытылса, яшь буын алар белән танышмаса, бу үкенечле нәтиҗәгә китерергә мөмкин.

Дини тәрбия элек-электән татар халкының традициясе булган. Дин мөмкинлекләрен куллану мәктәп укучыларында милли гореф-гадәтләребезгә мәхәббәт тәрбияләүгә, милли һәм дини үзаңнарын формалаштыруга уңай этәргеч булып тора. Шуңа күрә мәктәпләр мәчетләр белән тыгыз элемтәдә яшәргә тиеш.

Күптән түгел генә Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбенең IX сыйныф укучылары укытучылары Ә.Б. Заитова җитәкчелегендә “Коръән һәм көнчыгыш классикасы” дәресе кысаларында “Җәмигъ» мәчетендә булдылар.

Ә инде IV сыйныф укучылары укытучылары Г.Ә. Зөлкәрнәева белән “Ислам культурасының нигезләре” дәресе кысаларында әлеге



мәчеткә бардылар.

Зәйтүнә ханым Абдюшева һәм Гүзәлия ханым Абушаева балаларга экскурсия уздырдылар. Гүзәлия ханым ислам культурасының нигезләре турында әңгәмә корды, балалар әлеге тема белән кагылышлы сорауларга җаваплар кайтардылар, ребуслар чиштеләр. Әлеге очрашуда актив катнашучылар дини китаплар белән бүләкләнделәр. “Кроссвордны чиш” исемле конкурс игълан ителде. Шуннан соң өстәл артында үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре белән таныштылар. Чара азагында балаларны тәмле салма, плов, җиләк-җимеш, кайнар чәй һәм татлылар белән сыйладылар.

Мондый файдалы очрашулар дин нигезләре, аның асылы белән якынрак танышырга, югары әхлак сыйфатларын тәрбияләргә мөмкинлек бирә. Моның нигезендә укучыларда җаваплылык хисе арта, алар үз гамәлләренә әхлакый күзлектән карап бәя бирергә өйрәнәләр.

БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

# ÊӨÒÅÏ ÓÇÃÀÍ ÃÎÌÅÐ

*Повесть*

Зифа Кадырова




- Миңа «әнине үтерүче» диделәр, мин берни белмичә бардым. Сез әйтсәгез, мин моңа әзер булыр идем. Ышана алмыйм, ул бит үз аяклары белән керде, үләрлек түгел иде бит.

Илья авыр сулап куйды.

- Бик соң килгән иде шул, без дә, әле коткарырга өлгерербез, дип уйладык. Ә яргач, аның шеше бавыр-бөерләргә таралган булып чыкты, барысы берьюлы эшләүдән туктады.

- Ул яшәргә тиеш иде.

-Аңлыйм, бөтен кеше дә яшәргә тиеш. Без кагылмасак та, бер ай, һичьюгы ике ай яшәр иде. Искитмәле хатын-кызның сабырлыгына, ничек яшәгән ул шул хәлдә?

- Ике ай дисез, белеп яшәгән кешегә бик күп бит ул, аңа балалары яшәргә көч биргәндер. Ә сез беләсезме ник кире борылып чыкканын?

- Юк, белмим, без үзебез дә аптырашта калдык. Аннан тагын үзе килеп кергәч, без көнен күчерергә тәкъдим иттек аңа. Ул кире кергәндә дулкынланган иде, бер кергәч, кире чыкмыйм, диде, мин үтенечемне генә әйтергә чыктым, хәзер мин тыныч, дип, үзе ризалык бирде.

- Ул миңа үзенең дүрт баласын калдырып үлде, сез аңлыйсызмы безнең өстә нинди бурыч торганын? Мин сезгә ышандым, ә ул миңа.

- Кичерегез, мин Алла түгел, авыртканны җиңеләйтүче табиб кына.

- Ә мин монда күптәнме?

- Сезгә дулкынланырга ярамый. Сезнең бик яхшы дустыгыз бар икән, ул сезне вакытында китереп өлгертте. Мин аны иртәнгә тиклем кайтарып җибәрдем. Бәлки, гаиләгезгә хәбәр итәргәдер, тынычлап дәвалана алыр идегез.

- Юк, әйтмәгез, мин берәр нәрсә уйлап табармын. Үзегез әйттегез, кайбердә алдашу да кирәк. Тик сез миңа бер нәрсәне аңлатыгыз, миңа хәзер ничек яшәргә соң?

- Элек ничек яшәсәгез, хәзер дә шулай.

- Элеккечә булмас шул, элек мин Хәлимәне белми идем, аның балаларын, Любаны. Элеккечә яшәп булмас шул хәзер. Минем Люба хәленә калып та үләсем килми, миңа күпме калды дип тә сорамыйм, сез моны үзегез әйтергә тиеш, чөнки кешенең җирдә бетерәсе эшләре була.

Илья Рушаниянең кулын ычкындырмады, ул да тартып алмады. Ул бу сорауны көн дә, очраган саен көтте, аңа әйтү түгел, үз-үзеннән яшерде. Иелеп, иреннәре белән Рушаниянең кулына кагылды. Башын бик озак күтәрмәде, дөресен генә әйткәндә, аның сораулы карашлары белән очрашудан курыкты, күзләрен күтәрми генә: “Мин сезнең гомерегез өчен көрәшәчәкмен, тик сез дә миңа булышырга тиеш», диде кабат иреннәре белән аның кулына иелеп.

- Ничек? - дип пышылдады Рушания.

- Берни булмагандай, туган һәр көнне сөенеп каршы алыгыз, мин сезгә булышырмын, матурлык җирдә яшәргә тиеш.

Алар бер-берсен аңларга тырыштылар.

Иртәнге алтыда Рушания Сашага шалтыратты, трубканың теге башында иренең дулкынланып кычкырган тавышы ишетелде. Рушания сабыр гына тыңлап торды да: «Бар да яхшы, син борчылма, мин озакламый өйдә булам. Юк- юк, сиңа кайтырга кирәкми, кайткач аңлатырмын», диде. Рушания телефон трубкасын япты.

- Иртәнге самолет белән кайтып җитәм, диде, ни уйлап табарга да белмим.

- Рушания гына дип эндәшсәм, ачуланмассызмы?

- Ничек сезгә җайлы - шулай эндәшегез, ирем миңа Раечка, ди.

- Сезнең милләтегез кем, сер булмаса?

- Татар, ә бәлки башкорттыр.

- Мин дә шулайдыр дип уйлаган идем, мөселман хатыннары тыйнак, чибәр һәм бик түземлеләр. Сез дә бик сабыр кеше булса кирәк, тик шулай да сез бу качып йөрүләрегез белән һәрчак борчыласыз. Минем сезгә тәкъдимем бар - мин сезгә шәфкать туташы табып бирәм, ул сезгә өйгә килеп уколлар ясар, ә сез миңа ике атнага бер килеп күренеп торырсыз. Берәр төрле җиңелчә «чир уйлап табарбыз, сезнең өйдәгеләр өчен генә. Минем телефонны язып алыгыз, сез миңа һәркөнне үзегезне ничек хис итүегезне бәйнә-бәйнә сөйләп торырга тиеш, минем өчен бу бик мөһим, сөйләштекме?

Иртәнге сәгать уннар иде инде, Рушанияне Илья Ильич үзе озата чыкты. Самат инде ике сәгать көтеп утыра иде, ул аларга каршы торып чыкты.

- Хәлең ничек, Рушания, кайтабызмы?

- Кайтабыз, Самат, өйдә ни көтәдер?

- Кара әле, бәлки, сиңа абортка бардым дияргәдер, ә нәрсә, була торган хәл.

- Ни сөйлисең, - диде Рушания кызарып, - минем яшьтәме?

- Күптән түгел минем хатын барып кунып кайтты, нәрсәдер булган да кайтармадылар.

Аларны тыңлап торган Илья да:

- Мин аның белән ризалашам, сезнең яшьтә дә бик була торган хәл, юкка читенсенәсез, - диде. Рушания яшь кызлардай кып-кызыл булды.

- Юкса, ирегез әллә ни уйлавы бар, төн кунарга кайтмаган хатын турында ни уйларга була. Үзең аңлыйсың, мондый очракта ир-атның башына юньле уй керми. Ояласың икән дөресен әйт, җәфаланма. Барыбер бервакыт әйтергә туры киләчәк, шулаймы, доктор?

Доктор Рушаниядән күзен алмый гына Самат белән ризалашып баш селкеде.

-Уйлагыз, мин сезнең шалтыратуыгызны көтеп калам. Ә сез иртәгә иртәнге уннарга минем янга килегез. Шәфкать туташын бер ун көн йөртергә туры киләчәк, ә сез мин биргән киңәшләрне онытмагыз, берни булмагандай яшәгез.

Машина күздән югалганчы, Илья ишек төбендә басып торды. Язгы кояш күзләрне чагылдырды, тирә-якта кошлар чыр-чу килеп оя кордылар, сөенештеләр, язны сәламләделәр. Ул онытылып кошлар дөньясын күзәтте, монда җанга рәхәт иде, кире борылып керәсе дә килмәде. Анда чирлеләр, анда ялварулы караш, мең төрле сорау, анда күпме күз яше түгелә. Һәрберсенең гомере өчен көрәшәсең, үлем куенынннан йолкып аласың, ә коткара алмаганнары күзалдыннан китми, төшләреңә кереп йөдәтәләр. Алар да бу чир алдында көчсез, алар да үзләренең көчсезлегеннән башларын тотып елый, алар да Алла түгел, бары табиб кына.

Саматның таксие өй турына килеп туктаганда, капка алдында кызы белән улының машинасы тора. Чит машина килеп туктау белән капкадан атылып улы килеп чыкты, аннан Мәскәүдән кайтып җиткән Саша йөгерә-атлый килеп туктаган машинага ташланды. Самат аларны күреп:

- Мин әйткәннәрне онытма, кара йөзен - хәзер икебезне дә ботарлый, сакчылар көн дә кем белән йөргәнеңне дә әйткәннәрдер, син тыныч тот үзеңне, - диде.

Саша килеп алгы ишекне ачып җибәрде, күзләре акылсыз кешенеке кебек шардай булган, төн йокламаганнандыр, ахрысы, күз төпләре зәңгәрләнеп, асылынып төшкән, йөзе тартылып калган. Рушаниянең чыкканын да көтмичә, бер-бер артлы сорауларын яудырды.

- Рая, Раечкам, ни булды, ничек син шулай берсүзсез чыгып югалдың, ни булды? Без бит акылдан яза яздык. Раечка, сиңа ни булды, сине һәркөн чыгып китә, диләр сакчылар, ул ни дигән сүз, кайда йөрисең син, бу кем?

- Саша, әйдә, өйгә керик, монда яхшы түгел чит кеше алдында. Мин сиңа барысын да аңлатырмын. Ә бу Саматбезнең якташ. Үзең бит теләсә кем белән йөрмә дидең, менә шуңа бер генә такси белән йөрим. Әйдә, өйгә керик.

Рушания мөмкин чаклы тыныч булырга тырышты, юкса, эчтә әллә ниләр калтырый иде, җитмәсә, баш та әйләнергә генә тора. Ул акрын гына машинадан төште, Саша аны кочаклап алды.

- Раечка, уйламаган бер уй калмады, тукта, нишләп синнән дару исе килә?

- Тукта, таксига түлик тә өйгә керик. Сау бул, Самат, мин шалтыратырмын.

- Әни, син шалтырата алмадыңмыни? - дип улы килеп әнисенең битеннән үбеп алды. - Син алай шаяртма, әтигә инфаркт ясыйсың. Мин кая чабарга, кайдан эзләргә белмәдем.

- Гафу итегез, балалар, шулай килеп чыкты. Миң әтиең белән генә сөйләшим.Йортка керү белән елап шешенеп беткән кызы Алеся да чабып чыкты.

- Әни, әнием, - дип сүз әйтә алмый үксеп елады.

Рушания Хәлимәнең балаларын исенә төшереп,йөрәге кысып куйды, үзе дә елап җибәрүдән куркып, күкрәк тутырып сулыш алды. Кайда булганын белсәләр, нинди кара кайгы басачак өй эчен. Самат хаклы, оят булса да, аның әйткәне белән килешмичә булмый.

- Алеся, балам, тынычлан, бар да яхшы. Кызын кысып кочаклады. - Син чәй әзерлә, минем үтерепләр чәй эчәсе килә. Мин өсне генә алышыйм, әйдә, Саша.

Икенче катның йокы бүлмәсенә ул көчкә күтәрелде, Сашаның борчулы, сорау тулы күз карашын күтәреп торырлык түгел. Алдаша белмәгән Рушания дулкынлануын яшерергә тырышты, киемнәрне салып, өскә сеңгән дару исен тизрәк юып төшерергә, баштагы уйларны тәртипкә салып, тынычлап ял итәргә теләде. Ничек сүз башларга белмичә ул һаман сузды, Сашаның кабат сорау биргәнен көтте, ә ул җитди сораулы караш белән басып тора бирде. Рушания бүтән моны күтәрә алмый үзе сүз башлады.

- Саша, ник шул чаклы җинаятьчегә караган кебек карыйсың? Кил, утыр яныма.

Сашаның кыл кебек тартылган нервлары әнә-менә кабынып китәргә генә тора. Бер тәүлек билгесезлек аны акылдан яздыра язды. Ул акрын гына аның янына, үзләре йоклый торган карават кырына килеп утырды. Рушания аның күзләренә күтәрелеп карамаска тырышты, акрын гына, гаепле тавыш белән, ничек әйтсәм тотылмам микән, дип, көчкә сүз башлады.

Саша, оят инде әйтергә дә, сиңа белгертәсем дә килмәгән иде.

Саша тагын да кыл кебек тартылып:

- Нәрсәне? - диде сабырсызланып.

- Мин абортка бардым, менә шул, - диде иренең йөзенә күтәрелеп карап, үзе эчтән генә, беткән баш беткән, дип уйлап куйды.

Сашаның чырае башта агарды, куркыныч әйбер күргәндәй, бер яңагы тартып куйды, бик дулкынланса шулай була торган гадәте бар аның. Телсез калып, хатынына карап утыра бирде. Ниләр генә уйлап бетермәде шул бер тәүлек эчендә, тик мондый уй башына да кереп карамады. Саша көчкә зиһенен җыя алды, азрак йөзенә кан әсәре дә керә башлады, тотлыга биреп:

- Ничек? - дия алды. Ул утырган урыныннан идәнгә шуып гөште, Рушаниянең алдына тезләнеп, күзләрен олы итеп карап тора бирде.

- Гафу ит, Саша, оялдым әйтергә, карт бит инде мин. Көнендә кайтырмын, дип уйлаган идем дә, көтелмәгән хәлләр килеп чыкты, кайтармадылар. Иртәгә миңа өйгә килеп укол ясаячаклар, мин бүтән югалмам, - диде иренең күзләренә карап.

- Рая, Раечка, ник миннән яшердең? Ул Рушаниянең тезләренә башын салып, хатынын кочаклады. - Я Ходаем, ниләр башыма килгәнен белсәң! Ул башын күтәреп, яшьле күзләрен сөекле хатынына терәде. - Ник син һәрвакыт эчтән берүзең янасың, без бит бербөтен, ник минем белән уртаклашмыйсың? Мин бит ниләр генә уйламадым, үлгәнме, башка кеше белән киткәнме, миңа хыянәт иткәнме, башканы яратканмы?

- Гафу ит, матурым, тик бу хәлне башыма да китермәдем, белгән булсам, мин сине һич тә җибәрмәс идем. Ник алып кына кайтмадың? Син бит беләсең минем ничек синнән туган балаларыбызны яратканны. Дөрес эшләмәгәнсең.

- Тукта, ни сөйлисең, без бит инде әби-бабай була торган кешеләр, соң бит инде, мин дә карт бит.

- Нинди карт ди ул, әле монда, яшь кызлар кебек, авырга узып торганда. Сашаның йөрәге шашкын хисләр белән тулды, ул хатынын шашып-шашып үбәргә тотынды, аның кайнар тыны көйдереп-көйдереп ала, шашынып пышылдаган һәрбер сүзе йөрәкне куырып-куырып, Рушаниянең башын әйләндерә.

Әйе, карт та түгелләр шул әле, иллегә генә кереп баралар, шулчаклы хисләр ташып торганда, һәр күзәнәгең белән бер-береңне тоеп, сөю хисләре ташып, ике җан бер булып күкләргә очканда... Әйтерсең, алар унсигез - егермедә генә. Әле һаман башларыңны югалтып яратасы-ратыласы килгәндә, кем уйласын өеңнең бер почмагында кара шәүлә булып, әҗәл көтеп тора дип. Рушания барысын онытырга тырышып, иренең кайнар хисләренә кушылып китте, шушы мизгелләр аңа яшәргә көч бирәчәк, бүгенгесе белән яшәргә. Калган барлы-юклы гомереңне, һәр көнен якыннарыңа шатлык, мәхәббәт, җан җылысы биреп яшәргә, иртәгәсе өчен бүген борчылып елап ятмаска. Вакыт җиткәч тә өлгерермен, алар гына белмәсеннәр, бу дөньядан киткәндә артыңнан гөл бакчасы белән матур истәлекләр калсын. Мин моңа бар көчемне салырмын, мине яратканнарны мин дә яратырмын. Ах, Люба сеңлем, син ничаклы хаклы булгансың. Әле бу дөньядан китмәгән булсаң, Ходай үзе мәрхәмәтеннән ташламасын, әгәр инде китеп барсаң, авыр туфрагың җиңел, урының оҗмахта булсын, сеңелкәем.

Тормыш тагын үз җаена салынып китте, Самат, сөйләшкәнчә, көн дә укол ясаучы алып килде. Рушания аларны тәмле ризыклар белән сыйларга тырышты, хәле дә, кәефе дә бу көннәрдә яхшы, бакчасында казына. Быел да берни булмагандай, бакчасына күп итеп чәчкәләр утыртты. Кичләрен Саша белән икәү генә бик озак бакчада кочаклашып, кошлар сайравын тыңлыйлар. Май бәйрәмнәре дә җитте, йорт тагын дуслар, кунаклар белән тулды, сөенеп каршы алдылар, озатып калдылар. Рушаниянең эчке дөньясын беркем дә күрмәде, белмәде. Тик ул өйдә ялгыз калган минутларда гына мең сорау килә иде башына. Кеше үлгәч тә өч көнлек эше кала ди, аның да бит бу дөньядан киткәнче эшлисе эшләре, башкарасы вазифасы бардыр, кешеләр теге дөньяга ничек әзерләнеп барырга тиеш соң? Люба үлгәнче кылган гөнаһлары өчен өзгәләнде, үзеннән соң ятим калачак баласы белән иренең язмышын кайгыртты. Хәлимә балигъ булмаган, башлы-күзле ителмәгән ярым ачлы-туклы балалары өчен борчылды. Ходайга бик ышандымы, дүрт баланы ятим итеп алып китәргә намусы җитмәс дип уйладымы? Тик ул үләргә җыенмады, тик соңгы мизгелдә генә күңеленә шик керде һәм бөтен вазифасын Рушаниягә өеп калдырды. Хәзер аның өстендә дүрт бала язмышы. Әниләрен берни белән дә алыштыра алмый. Лилия дә рәнҗеде, һичьюгы утырып сөйләшер-аңлашырлар иде бит әле. Юк шул, эчендәгесен бүлешер кешесе дә юк. Ул инде моңа күнегеп бара. Ул шалтырата да: «Рушания, хәлең ничек?» ди. «Менә утырам, башымда мең төрле сорау, ни сорар, ни киңәш бирер кеше юк». «Ә син көндәлек алып бар, аңа барысын да сөйләргә була, ул аңламаганны миңа сөйлә, мин дә тыңлый беләм». Менә шулай алар көненә бер аралашып алалар.

Рушания, Хәлимәнең җидесен уздырырга Саматка акча бирде.

Ни кирәк - барысын да алып бар, базардан иң яхшысын, иң тәмлесен ал, мөмкин булса, хәер дә өләш.

Самат базарга хатынын алды, хатын-кыз яхшырак белә ни кирәген, алар барлык кирәк-яракны җыеп, хатыны белән бергә илттеләр. Лилия каршы чыкты:

- Кирәкми бер нәрсәсе дә, гаебен акча белән капламакчымы, Әни китте, ә ул яши...

- Тукта, кызый! - Самат кычкырып җибәргәнен сизми дәкалды, хатыны артына төрткәч, тиз генә үзен кулга алды. - Әлегә Рушания апаң бар сезне кайгыртырга, озакламый ул да китәр әниең артыннан, ул чакта кемгә үпкә сакларсың?

Карт әби килеп Саматның беләгенә кагылды.

- Куй, балам, ни сөйлисең? Балаларга үпкәли күрмә, алар әле бала гына. Шундый матур, су сөлеге кебек хатын нишләп китсен, ди. Әйдә әле, керегез, кер, утырыгыз, сөйләшик. Син, улым, Рушаниягә балалар сүзен кабатлый күрмә. Авыр шул балаларга әнисез. Әйтәм дә бит, беркем дә бер-берсенә начарлык теләми, Ходай шулай кушкач, нишлисең бит. Рәхмәт, дип әйтте Нурлыбанат әби, диярсең. Аның ярдәме белән балаларның тамаклары тук. Берүк чирли күрмәсен, аңа инде рәхмәтләр укып, догалар кылам, улым. Әйе, шулай диген, берәр килсен иде, сөйләшеп утырыр идек, бигрәкләр дә матур бала.

- Әбекәй, әллә берәр көн үзеңне аның янына алып барыйммы соң? Ул хәзер өйдә генә дәвалана, ул көннәр буе ялгыз утыра бит.

- Ник бармаска, барырбыз, Алла теләсә, әллә һаман чирлиме?

- Шәптән түгел, гаиләсе белми, әйтергә кушмый. Сез барсагыз, бәлки, сөйләшер, догалар укыр идегез.

- Ярый, улым, син бер атна-ун көннән килеп алырсың, әлегә балалар янында торам. Барам, Алла теләсә, барам.

Самат икенче көнне Рушаниягә сөйләгәч, аның елмаюын, яшьле күзләрен күреп, үзе дә исе китеп карап утырды, чынлап та, искитмәле кеше, җир бизәге бу Рушания.

- Чын әйтәсеңме, Самат? Минем дә әнием бар иде бит, ул үлгәннән соң мин бөтенләй ятим калдым. Ул гел минем әнием төсле. Син алып кил аны, син бик дөрес эшләгәнсең аны чакырып. Инәйләр олы йөрәкле, миһербанлы булалар, ә түземлекләренә исең-акылың китәр, безгә алардан күп нәрсәләргә өйрәнәсе бар шул әле.

Рушания бераз уйга чумып утырды.

- Минем Нурлыбанат әбигә бик күп сорауларым бар, син аны, зинһар, алып килә күр. Самат, соңгы вакытта син миңа туганым кебек якын, нишләп элегрәк очрашмадык икән? Шулай да сиңа бер үтенечем бар.

Рушания ничек аңлатырга дигәндәй, тагын уйга чумды, кирәкле сүзләр эзләде, аннан күзләрен Саматка күтәрде.

- Мин сездән ахыргача мине ташламавыгызны сорар идем.

Самат берсүзсез Рушаниягә карап торды да, ярар дигәннеаңлатып, баш селкеде. Алар бер-берсен яхшы аңладылар.

Рушания кунакларга, шау -шулы җирләргә бик йөрмәскә тырышты, күбесенчә үз бакчасында чокынды. Элекке кебек йөгерә-йөгерә эшли алмаса да, хәленнән килгәнне барысын да үзе эшләде. Урман яклап койма буена килеп, тиеннәрен чикләвек белән сыйлады, ә алар рәхмәт йөзеннән арлы-бирле сикереп аның күңелен күрделәр. Рушания аларга карап сокланып туймады. Беркөнне шулай бакча буйлап йөргәндә, аңа таба килгән олы гына бер керпегә тап булды, артыннан кечерәк баласы да ияргән. Рушания сөенеченнән кычкыра да алмый катып калды, ә алар берни булмагандай алмагачларга таба юл тоттылар. Рушания ашыга-ашыга өенә кереп, алмалар алып чыкты, алар белән сөйләшә-сөйләшә алларына алма салды. Алар башта куркып бөтәрләнделәр, керпеләрен кабарттылар, тик алманың хуш исе кыш буе сагынган алмаларны авыз итәргә мәҗбүр итте. Шул көннән башлап алар һәркөн диярлек килмичә калмадылар. Рушания шушы телсез тере җаннар белән очрашуына сөенеп бетә алмады. Алмагачлары быел да шау-гөр килеп чәчкә аттылар, һәрберсенә атап утыртылган алмагачының иң тәмле алма биргәнеРушаниянеке иде - «Башкорт чибәре». Ул аның чәчкәләрен иснәп елмайды. Ул ел да алмалар өлгерсә, кая куярга белми җәфалана, килгән берәүгә тутырып җибәрә. Быел, Алла бирсә, Хәлимәнең балаларына тутырып җибәрермен, әйдә, ашасыннар туйганчы. Рушания ничек тә төшенкелеккә бирешмәскә тырышты, шушы кечкенә табигать кочагында шушы кечкенә җәнлекләр белән юанды, күңелсез уйларны ераккарак куарга тырышты, ул аларны күңел түренә яшерде, читләр генә түгел, үз-үзеннән дә яшерергә тырышты.

Рушания зарыгып көткән көн дә килеп җитте, Самат иртән шалтыратып:

- Бүген төшке якта әзерләнеп тор, Нурлыбанат әбине алып ниләм, - дигәч, Рушания сөенечтән кая басарга белмәде, тиз- тиз аш әзерләде, бәлешен салып җибәрде, бар авыртуларын онытып, элекке кебек очып кына йөрде. Өстәл тутырып тәмле ризыклар әзерләде, ул аны кадерле туганын көткәндәй көтте. Капка төбендәге сакчыларга да әйтеп куйды, килү белән кертеп җибәрсеннәр. Капкадан ак яулыклы кечкенә әби күренү белән әллә ничек күңеле тулып китте, үзенең карт әнисе исенә төште. Исән булса, ул аны өрмәгән җиргә дә утыртмас иде, юк шул. Рушания ашыга-ашыга килгән кунакларга каршы чыкты, аның шатлыгы йөзенә үк чыккан, гел елмаеп кына тора.

**Дәвамы бар.**

**25 ноябрь - илебездә Әниләр көне билгеләнә**

# ӘНИЛӘР ЯМЬЛИ ДӨНЬЯНЫ

***– Балам, тор, мәктәпкә соңга каласың... Әнинең йомшак, ягымлы тавышы. Иртән чәчеңнән сыйпап әйткән җылы сүзләрен ишетү шундый рәхәт. Күңел иркәләнә, ләззәтләнә, ә йокы һич тә бирешергә теләми....***



Һәр балага да әни кирәк. Әмма язмыш күп кенә сабыйларны ятимлек авырлыгы белән сыный. Бәхетләренә яхшы күңелле үги ана эләгә. Ятим, карачысыз калган балаларны гаиләсенә кабул итеп, аларны үз сабыйлары кебек яратучы, игътибар һәм наз бирүче әниләргә, һичшиксез, һәйкәл куярлык. Иске Кулаткы эшчеләр бистәсеннән Гөлфия Равилевна Курмаева да үзенең ике баласын үстергәч, гаиләсенә тагын биш сабыйны сыендырып, аларга әни җылысын бүләк итеп яшәүчеләрнең берсе. Гөлфия апа 18 ел дәвамында "Гөлчәчәк" балалар бакчасында тәрбияче булып хезмәт итә. Тормышында бик күп авырлыклар кичерергә дә туры килә аңа. Балаларының әтиләре ташлап киткәч, ул ялгызы гына ике улын тәрбияләп үстерә, төпле белем үзләштерергә һәм югары уку йортларына укырга керергә ярдәм итә. Авырлыкларга сабыр гына түзәргә өйрәнгән Гөлфия апа, беркайчан да тормышыннан зарланмый һәм балаларын да шуңа өйрәтеп үстерә. Бүгенге көндә ике улы да югары уку йортларында белем ала. Гамиле – Самара шәһәренең медицина университетын тәмамлый, ә Эмиль Ульяновск шәһәренең авыл хуҗалыгы академиясендә укый. Гөлфия апа тәрбиягә алган балаларны үз нарасыйлары кебек якын күрә. Һәрберсе белән уртак тел табып, аларның яралы җаннарын дәваларга тырыша.

-Улларымны бик яратам, тик күңелемдә һәрвакыт кыз үстерү теләге дә яшәде. Ятим балалар белән эшләүче оешмага мөрәҗәгать иткәч, миңа үз районыбыздан ук бертуган балалар – ике малай һәм бер кыз барлыгы турында хәбәр иттеләр. Ике малай үскәнне тагын икесе дә үсәр, дидем. Бу язулы сабыйларның әниләре "яшел еланны" үз иткән һәм балаларының сәламәтлегенә һәм гомеренә куркыныч янагач, аларны бу гаиләдән алалар. Менә шулай Юлия, Марсель һәм Фәнилне өебезгә алып кайттык. Ике елдан соң Динарны, озак та үтмәде нәни Дамирны да гаиләбезгә сыендырдык. Бертуган сабыйларны ничек аерасың инде? Хәзер инде Марсель, Юлия һәм Фәнил минем ярдәмчеләрем. Бер - берсенә дәресләр хәзерләргә ярдәм итәләр, нәни энеләре өчен өзелеп торалар. Ничек менә шундый "татлы бәләкәчләрне" яратмыйсың инде.

Шушы балаларның мәшәкатьләренә күмелеп, һәрбер уңышларына куанып яшәгән әни, бүген алардан башка үзенең тормышын күз алдына да китерә алмый.

- Гөлфия Равилевна – бик җаваплы, кайгыртучан әни. Үз гаиләсенә сыендырган балаларны акыллы, тәртипле итеп үстерү, аларга тиешле тәрбия бирү өчен бар көчен куя ул. Балаларның укулары белән һәрдаим кызыксынып торучы, аларның сәләтләрен тагын да үстерү өчен җырбию түгәрәкләренә йөртүче әнигә сокланмау мөмкин түгел, - дип сөйли Иске Кулаткы беренче номерлы башлангыч сыйныфлар укытучысы С. М. Атауллина.

25 ноябрь көнне Әниләр көне бәйрәме уңаеннан Ульяновск шәһәрендә үтәчәк бәйрәм церемониясендә Губернатор С. И. Морозов тарафыннан Гөлфия Равилевнага III дәрәҗәле "Ана Даны" ордены тапшырылачак. Шундый дәрәҗәле бүләккә лаек булуы уңаеннан без дә Гөлфия Равилевнаны кайнар котлыйбыз һәм ныклы сәламәтлек, бәрәкәтле озын гомер, ак бәхетләр, гаиләгезгә иминлек телибез. Газиз балаларыгызның игелеген күреп, яраткан әни булып, шатланып-куанып яшәүләр насыйп булсын!

***Кем өчен дә иң беренче***
***әни кирәк.***
***Юктыр җирдә әниләрдән***
***кадерлерәк.***
***Егылсак та, еласак та***
***әни кирәк.***
***Шатлыкта да, кайгыда***
***да безгә терәк.***
***Әни назы, әни сүзе сеңсә***
***күбрәк,***
***Абынулар, ялгышулар***
***була сирәк.***

**Гөлназ КУЗӘЕВА.**

# БЕРКАЙЧАН ДА ТОРМЫШЫҢНАН ЗАРЛАНМА!

Аллаһ ишетеп: "Синең әле авыр тормыш күргәнең юк" – дип, күпкә авыррагын бирер. Ни генә булса да "Аллага шөкер, тормышым шәп", дип яшәргә кирәк. Шунда Аллаһ: "Әле синең әйбәт тормыш күргәнең юк", дип, тагын да әйбәтрәген бирер. Бүгенге җомга вәгазен Рөстәм хәзрәт тормыштан канәгать булмаучы, һәрчак зарланырга яратучылар өчен гыйбрәт итеп сөйли.

– Иң элек бер риваять китереп китәм. Кечкенә генә шәһәр читендә әнисе белән бер малай яшәгән. Әлеге бичара хатынның ире дә булмаган, улы белән бик тыйнак кына яшәгәннәр. Тормышлары бер дә җиңелләрдән булмаган, тик алар Аллаһы Тәгалә биргәнгә шөкер кылып яшәгәннәр. Бары тик кыш көне генә, яисә яңгырлар яуганда гына бераз уңайсызлык кичергәннәр. Чөнки аларның йортлары дүрт стена һәм ишектән генә торган, түбәсе юк. Бу малайга дүрт яшьләр булганда, бик каты болыт килеп, шәһәр читендә көчле яңгыр ява башлый. Бөтен кешеләр яңгырдан качып, үзләренең җылы өйләренә чаба-чаба таралышалар, ә бу хатын улы белән икәү әлеге кыен хәлдә калалар. Малай хәлнең нәрсәдә икәнен аңлап, моңсу күзләре белән әнисенең кочагына сыена. Тик малайның да, хатынның да киемнәре лычма юеш. Шул чак хатын ишекләрен каерып ала да, стенага сөяп куя һәм улы белән яңгырдан ышыкланып шуның астына кереп утыра. Сабый үзенең эчкерсез, тик бик бәхетле күзләре белән әнисенә карап: "Әни, ишекләре булмаган кешеләр бу яңгырда нишлиләр икән, без, Аллага шөкер, ышыкта", – ди. Бу малай шул мизгелдә үзен бик бәхетле, бай итеп хис итә. Әлеге риваять пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в. хәдисен искә төшерә: Аллаһы Тәгалә биргән һәр нәрсәдән канәгать булырга кирәк – шул чакта иң бай кеше булырсың.

Аллаһ бәндәләрне бар итте, ризык бирде. Теләгән бәндәсенә ризыкны күбрәк, теләгән бәндәсенә ризыкны азрак бирде. Хәмед белән шөкер итәбез, гөнаһларыбыздан Аңа кайтабыз. Ул ялгызы, юк аның тиңдәше. Мөхәммәт – Аның илчесе. Салават шәрифләребез аңа булсын.

Кешелек дөньясы диннән ерагайган саен, җәмгыятебездә тискәре сыйфатлар артканнан-арта бара. Аллаһы Тәгалә мул, чиста итеп биргән суларның балы бетә, корсаклар тулы булса да, ризыкның бәрәкәте бетә. Карыннан үткән ризык та, оят җирләрен яшерүче кием дә, утыртып йөрүче ат та ул авыруны канәгатьләндерә алмый. Канәгатьсезлек, ризасызлык авыруы белән агуланган бәндә тотып карардай ризык белән туя алмый, киеп карардай кием белән канәгатьләнә алмый, утырып йөрердәй ат, машинадан канәгать була алмый. Ихтыяҗы үтәлә, машинасы да бар, йорты яңгыр-давылдан саклый, ләкин кешегә ул җитми. Ләкин күбрәк булса, яхшы булыр иде ди. Аллаһы Тәгаләгә шөкер итми, булганына шөкер итәргә кирәк дип үз-үзен вәгазьләми. Күп булса да, ул бәндәгә җитми. Нинди генә нигъмәтләре булса да, Аллаһ нинди генә мул тормыш бирсә дә, ул бәндәгә барыбер җитми, чөнки ул авыру бәндә, сәламәт бәндә түгел. Аның тәне сәламәттер, ләкин күңеле авыру. Шушы канәгатьсезлек авыруы белән чирләү сәбәпле, аңа күп булса да, җитми. Җитәр дип уйлаган халәтенә ирешә икән, аннары барыбер җитми икән. Ни өчен җитми? Чөнки авыру, аның күзе һаман да өскә таба карый, "Әлхәмдүлилләһ, кайчандыр ул нигъмәтем дә юк иде, хәзер бар", – дими. Өскә карый да: "Кара. Ул миннән дә яхшырак", – ди. Ялангач йөрми, киеме бар, "Аның киеме тагын да затлырак", – ди. Аты бар, "Аның аты затлырак", – дип, һаман өскә карый. Үзеннән түбән дәрәҗәдә, яманрак халәттә булучыларга күзен төшерә алмый. Табигатькә карасак, һәрбер нәрсәне төшерүгә караганда күтәрү авыррак. Күтәргәндә, җир тартып тора, шуңа күрә, күтәрү авыррак. Кулны күтәрү төшерүгә караганда авыррак. Ятактан тору авыррак. Күз байлык эзләсә, киресенчә, төшерергә авыр икән.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: "Үзеңнән баеракларга карама, ә ярлыракларга карап шөкер ит". Ризасызлык белән авыручы үзеннән өстенрәкләрне карый. Аңа җитмәгәч, бервакытта да бәхетле була алмый. Кешенең 10 байлыгы булса да, барыбер үзеннән өстен кешене табар. Аллаһның гадел үлчәве дә бар. Бер яктан камиллеккә ирешсә, икенче яктан кимчелеккә төшә. Гыйлем алып, кемнеңдер иманы куәтләнергә мөмкин, ләкин сәүдәсе кимеп китәргә мөмкин. Кемнеңдер сәүдәсе артып, гыйбадәте кимергә мөмкин. Шуңа күрә, кеше бервакытта да төгәл камиллеккә ирешә алмый. Ризасызлык белән агуланган бәндә бер вакытта да үзе теләгән бәхеткә ирешә алмый, чөнки Аллаһ аңа бу хәлне бирми. Әгәр дә ризасызлык белән яшәгән кешегә шушы Җир шарының яртысын кисеп бирсәң, валлаһи, ул беренче төнне үк йоклый алмаячак, чөнки икенче яртысы кемгә икән дип борчылачак. Адәм баласының канәгатьсезлек авыруы зур бер сынау. Бу чирдән дәваланырга кирәк. Аллаһның биргән нигъмәтләрен күрә белергә, алар өчен шөкер итәргә кирәк. Шул вакытта Аллаһы Тәгалә киемнең дә, ризыкның да бәрәкәтен бирер. Ризык калориясе күп булганга туйдырмый. Ризыкта бәрәкәт булса, тамак туя. Шуңа күрә, Хандак сугышында сәхабәләр пәйгамбәребез (с.г.в.) белән ач булганда, хәтта, ачлыкны аз гына булса да басып торсын дип, корсакларына ташлар бәйләп куйдылар. Пәйгамбәребезнең күлмәге астында ике таш бәйләнгән иде, ул да сыналды. Бер сәхабә, пәйгамбәребезне кайгыртып, өенә кайтып, бер бәрәнне чалдырды. Хатынына: "Әзерлә әле бәрәнне, хәзер Аллаһның илчесенә алып кайтып ашатыйк", – диде. Кечкенә генә бәрәнне чалып, хәләл җефете шулпа пешерде. Бу сәхабә Пәйгамбәребез янына килеп, "Әй, Аллаһның илчесе", – дип, колагына гына пышылдады. Сәхабәләр бик күп иде. Ә бәрән кечкенә булды. "Кечкенә генә ризык әзерләгән идек, әйдә, кайтып ризыклан", – диде. Пәйгамбәребез (с.г.в.) чокыр эченнән чыкты да: "Кардәшебез безгә ризык әзерләгән. Әйдәгез, ашыйбыз", – диде. Теге ризык әзерләүче сәхабә, хатыны янына кайтып болай диде: "Һәлак булдык, Аллаһның илчесе барлык сәхабәләр белән безгә кайта". Чөнки ит шулкадәр кечкенә булса да, сәхабәләр бик күп һәм ач иделәр. Шул вакытта теге сәхабә әйтә: "Барлык сәхабәләр дә туйганчы ашадылар, соңыннан Аллаһ илчесе белән бергә утырып ашадык". Аллаһ бәрәкәт бирә икән.

Әгәр күпме генә ризык булса да, Аллаһ бәрәкәт бирми икән, кеше шул ризыктан бәхет күрә алмаячак. Канәгать булу ул зур нигъмәт. Аллаһ аны кемгә бирде, шөкер итсен, шатлансын. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дога кылды: "Әй Аллаһ, биргән ризыкларыңда миңа канәгатьлелек бирсәң иде", – диде. Аллаһтан муллык кына түгел, канәгатьлелек тә сорарга кирәк. Җир өстендә иң канәгать кеше Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) булды. Зур-зур патшалар, кәрваннар белән алтынга күмелсәләр дә, пәйгамбәребез кебек разый булып яшәмәделәр. Пәйгамбәребезнең берничә көн мичендә уты янмаса да, аның кебек канәгать кеше булмады. Пәйгамбәребез (с.г.в) әйтә: "Беркөнне Аллаһ Мәккә үзәнлекләрен алтынга тутырырга тәкъдим итте. Ләкин мин юк, кирәкмәс, Раббым, дип әйттем. "Бер көн ач булыйм, бер көн тук булыйм. Әгәр тамагым ачса, Сине зикер итәрмен, әгәр тамагым тук булса, Сине шөкер итәрмен". Әлхәмдүллилләһ, мөселман муллыкка ирешсә, Аллаһны мактый, сынаулар килсә, Аллаһны зикер итә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) тормыштан канәгать булып, Аллаһ биргән сынауларны гайрәт белән кабул итүчеләргә шатлыклы хәбәр әйтте: "Түбә агачы җәннәттә кемгә булыр? Кемнең тормышы җитәрлек кенә булып, ислам динендә булса. Очын-очка ялгап, тормышын алып баручы кешегә булыр", – диде.

Раббым һәрберебезгә канәгатьлелек насыйп итсен. Бик күпләр авырый торган ризасызлык дигән авырулардан безгә шифа бирсен.

**Матбугат.ру сайтыннан алынды.**

**РЕКЛАМАЛАР ● БЕЛДЕРҮЛӘР ● КАЙГЫ УРТАКЛАШУ**

## АТА – АНАЛАР БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ

Кайбер ата-аналар бала тәрбияләү өчен вакыт җитмәүне, кайберләре ничек тәрбияләргә белмәүне сәбәп итәләр. Хәзерге болгавыр чорның үзгәрешләре гаиләдә ата-аналарның бала тәрбияләвенә тискәре йогынты ясый. Бала әти-әнисе белән аз аралаша, күбрәк компьютер каршында утыра, хәтта дуслары белән дә ул интернет челтәре аша гына сөйләшә. Ә ата-ананы исә, ничек эш урынында калырга, кешедән калышмыйча киенергә, ашарга-эчәргә, машина алыштырырга, кайберләрен хәтта ничек байлык тупларга, дигән уй күбрәк борчый. Бүгенге көндә күпчелек ата-ананың тәрбия мәсьәләләренә исе дә китми, күбесе вакыт-вакыт кына, ә кайберләре бөтенләй балаларны тәрбияләү белән шөгыльләнмиләр. Ә бит гаилә тәрбиясен кем дә алмаштыра алмый. Кызганычка каршы, Иске Кулаткы районы буенча Павловка районара эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаганнар инспекциясендә балаларына начар йогынты ясаучы 32 ата-ана исәптә тора. Ә бит балалар - гаиләнең көзгесе. Шәхси үзенчәлекләре булуга карамастан, балаларда гаиләнең холкы чагыла.

Гаилә дөньясы. Ул әти һәм әни, сеңел һәм энеләр яши торган дөнья. Һәр бала гаилә тормышы аша зур дөнья белән таныша. Бала анда яхшыны да, начарны да, вөҗданлык һәм тәрбиясезлекне дә күрә. Кешенең формалашуы авыр һәм күп көч сорый торган хезмәт. Тәрбия эшендә вак нәрсәләр юк, монда барысы да бала күңелендә күпмедер дәрәҗәдә эз калдыра. Аз гына күреп җиткермәдеңме – кеше туры юлдан читкә тайпылырга мөмкин.

Үзара хөрмәт һәм ышаныч хөкем сөргән, хезмәт яраткан гаиләләрдә яхшы яки начар эшләре өчен үзе җавап бирергә тиешлеген инанган кеше үсә. Бала, кечкенә чактан ук, ярамаган эшләр өчен җавап биреләчәген белергә тиеш. Әкренләп аның психикасында тыя торган киртәләр барлыкка килә, соңрак психик карашы формалаша.

Законны хөрмәт итү дә гаиләдә тәрбияләнергә тиеш. Биредә әти белән әни – бала өчен беренче укытучы. Аларны үз эшләренә, әйткән сүзләренә, бурычларына мөнәсәбәте бала өчен үрнәк.

Балалар үсеп җиткәнче, вакытларының күп өлешен ата – аналары янында уздырган бер чорда аларга урамда ничек тәртипле булырга, табигатьне ничек сакларга, авыруларга, картларга ничек ярдәм итәргә кирәклеген турыдан – туры өйрәтергә зур мөмкинлекләр бар

Ата – ана мәхәббәте баланы киң күңелле, ягымлы, ачык йөзле итә. Шушы мәхәббәт җылысы балада намуслылык, йомшак күңеллелек тәрбияли. Балаларыбызга игътибарлы булыйк, вакытыбызны кызганмыйк, һәм тәрбияле шәхесләр итеп үстерик,

**Юлия Усманова, Павловка районара полиция бүлегенең балигъ булмаганнар эше буенча инспекторы, өлкән лейтенант.**




● Окна от производителя
+ комплектующие
● Двери «Бульдорс»
● Натяжные потолки
(от 240 руб./в.м)

**Телефоны: 88422(651832), 89041823507, 89374550649.**

В УЛЬЯНОВСКИЙ ФИЛИАЛ ООО «ИМИДЖ»
приглашает на постоянную работу
**ТОРГОВОГО ПРЕДСТАВИТЕЛЯ**
с личным автомобилем
Условия: график работы 5/2,
(Старая Кулатка)
З/п до 40 000 руб.
Реклама. ОГРН 4021300978820
**Тел. 8-927-634-57-59**

### ООО «Немецкие оконные изделия»



1. Заводское производство.
2. Гарантия качества.
3. Короткие сроки.
4. Установка входных и межкомнатных дверей.
5. Выезд на замер бесплатно.

При заказе 3 окон - жалюзи в подарок
При заказе 4 окон - дверь входная в подарок.
При заказе 5 окон - шестое окно в подарок.

Рассрочка и скидки!!!

*Условия акции по тел.: 89020040102; 89374588644; 89278018665.*

***Супер акция - окно из прорфиля 70 мм. по цене окна из профиля 58 мм.***

## ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА

**Производство и установка пластиковых окон.**

**При заказе пяти окон, шестое – бесплатно! Замер, доставка – бесплатно.**

***Наше качество и доступные цены порадуют вас! Пенсионерам – дополнительная скидка!***



20% скидка

**Телефон: 8-937-278-05-55.**
Павловка.

## Скорая компьютерная помощь



ИП «Шафиева» предоставляет услуги по установке, настройке, а также по ремонту компьютерной техники.

Профессиональный ремонт компьютеров и ноутбуков. Установка WindowsXP/7/8/10; Удаление вирусов, установка антивирусника; Очистка от пыли и грязи при перегреве; Оптимизация работы компьютера и многое другое. Выезжаю в села, работаю с организациями. Цены приемлемые. Действует скидочная система. Заказы принимаются круглосуточно.

Мы находимся по адресу: р.п. Старая Кулатка, в здании магазина «Магнит» на втором этаже, 1 павильон слева. Звоните по телефону: 89279837788 (Марс).

## Магазин “Квадратный метр”

Предлагает Вам бытовой линолеум “Линостар” по цене 165 рублей за квадратный метр! И большой ассортимент линолеума Таркет, Синтерос и Полистиль.

В продаже также имеется металлопрокат и огромный выбор хозяйственных товаров

Ждём Вас в по адресу: р.п. Старая Кулатка, ул. 50 лет Победы, 19, тел.: 8(927) 984-11-82; (84249) 2-28-15

## Стоматология ООО «Дента Люкс»

приглашает вас воспользоваться качественными услугами современной стоматологии

пациентам нуждающимися в протезировании готовы предложить:



- съемное протезирование: протезы из акриловых пластмасс, бюгельные, нейлоновые;
- несъемное протезирование: коронки с покрытием, металлокерамические, комбинированные, цельнолитые и.т.д.

Запись предварительно по тел.: 89278033404, Пионерская, 18 А. Консультация бесплатно.


## РӘХМӘТЕБЕЗНЕ КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

Берәр җиребез авырта башласа, без больницага мөрәҗәгать итә. Безнең белән дә быел шундый хәл килеп чыкты. Яңа Мостяк авылында бергә яшәүче тормыш иптәшем Сәмәт Яхьевич Абсатдаров каты авырганнан соң, район больницасында дәваланды.

Авыру кешене кайчан-кайчан ягымлы һәм җылы сүз дә дәвалый, диләр. Нәкъ шул әйтем больницаның яшь табиб-терапевты Әлфия Рафаэлевна һәм аның тормыш иптәше, медицина энекәше Алексей Николаевич Масовларга туры килә дә инде. Алар минем тормыш иптәшемне беренче көннән ук ягымлы итеп каршы алдылар. Диагнозын билгеләп, күңелләрен биреп, дәвалый башладылар. Ходайга шөкер, бу медицина хезмәткәрләренең тырышлыгы нәтиҗәсендә ике атна үтүгә тормыш иптәшем аяк өскә басты һәм бүген дә үзен бик яхшы хис итә.

Намуслы хезмәтләре, тырышлыклары өчен без чын күңелдән Әлфия Рафаэлевна һәм Алексей Николаевич Масовларга олы рәхмәтләребезне белдерәбез.

**Равза Исхаковна һәм Сәмәт Яхьевич Абсатдаровлар.**
**Яңа Мостяк авылы.**

Продается автомашина "Газель", грузопассажирский. В подарок - зеркальные номера. Торг уместен. Тел: 89278038522.

Организация реализует кур-несушек с доставкой на дом. Тел.: 89298156785.

Продается дом по ул. Нижне-Северная, площадь 60 кв.м. Газовое отопление. Центральное водоснабжение. Участок 27 соток. Возможен обмен на квартиру. Телефоны: 8-929-797-34-34, 8-927-833-19-99.

Продаем гаражи металлические (пеналы) новые и б/у. Размеры любые. Доставка бесплатная. Цена от 26 тыс. руб. Тел.: 89063969864; 88007009091.

Утерянный военный билет на имя Сафина Радика Рафаэльовича считать недействительным.

Куплю пух-перо гусиные новые, старые перины, подушки. Дорого. С выездом на дом. Телефон: 89373886444.

Реализуем пиломатериалы по р.п. Старая Кулатка: обрезные пиломатериалы – по 6500 рублей, необрезные – 4500 рублей, с доставкой. Телефон для справок: 84248 – 2 – 19 – 19.

Продается сено в рулонах с доставкой на дом. Телефоны: 89278022734; 884(239)44514.

Закупаем говядину (быков, коров, телок). Вынужденный забой. Телефон: 89276002299.

Продается деревенское, индюшиное мясо халяль. Тушки - от 4 кг. Цена – от 280 руб. Также в продаже: пшеница, жмых, фураж. Недорого. Телефон для справок: 89278093172.

В р.п. Радищево продается «ВАЗ-21124», 2004 года выпуска, цвет – графитовый металлик. Телефон: 89370371980.

Безнең өчен иң кадерле, иң якын кешебез яраткан тормыш иптәшем, әтиебез, бабакаебыз, абыебыз, җизнәбез **Рәхимҗан Хөсәинович АХМЕРОВНЫ** хөрмәтләп, соңгы юлга озатуда катнашкан, ярдәмләшкән, кайгыбызны уртаклашкан өчен туганнарга, тирә-күршеләргә, дусларга, тәп кунучы әбиләргә, башкаручы бабайларга, “Транстехсервис” хезмәткәрләренә һәм җитәкчеләре К.Р. Абдрәзәковка, Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе коллективына, хәзрәт Р.Б. Файзуллинга, Г.Ю. Воиновка, Ж.И. Ханбиковка, И.А. Ахтәмовка зур рәхмәтләребезне белдерәбез. Ходай Тәгалә исәнлек-саулык, озын, бәхетле тормыш бирсен. Якыннарыгызның һәм үз гомерегезнең кадерен белеп яшәгез, чөнки беркем белми, алда ни буласын!

**Ахмеровлар, Едихановлар, Абдуллиннар, Ханбиковлар, Ахтәмовлар, Сөләймановлар.**

Иске Кулаткы – Самара – Саратов.

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, хезмәт ветераны, "сугыш елы баласы" **Роза Сафовна УМӘРОВАНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының һәм туганнарының тирән кайгыларын уртаклашалар.

Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе коллективы хезмәткәр **Рәхимҗан Хөсәинович АХМЕРОВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, гаиләсенең, туганнарының кайгыларын уртаклашалар.


Директор-баш редактор
М.С. Масиева.

Адрес редакции, издателя:
433940
р.п. Старая Кулатка
Ульяновской области,
ул. Куйбышева, 22.
ОАУ Редакция газеты
"Кумяк кюч".

**Телефоннар:**
электрон адрес:
kumiakk@mail.ru
884(249)2-11-94-редактор,
факс, бухгалтерия;
884(249)2-12-64 - журналистлар, реклама бүлеге, РИК операторлары.

Индекс 54505.
Газетаны басарга кул кую вакыты:
график буенча - 16.00
фактта - 16.00
Тираж 2600
Заказ № 13/47
Распространяется по подписке.

Газета отпечатана с готового оригинала-макета в ООО «Принт Хаус»
432071, г. Ульяновск, ул. Федерации, 15.

Элемтә һәм масса - күләм коммуникацияләр сферасында күзәтү буенча Федераль службаның Ульяновск өлкә идарәсе 2014 елның 21 ноябрендә ПИ №ТУ73-00388 номерлы масса-күләм информация чарасын регистрацияләү таныклыгы белән регистрацияләнде.

Газета битләренә урнаштырылган рекламалар һәм белдерүләр өчен редакция җаваплылык тотмый.

Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Хатлар, кульъязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.